Казан шәһәре Совет районы "Күп профильле 181 нче мәктәп"

# «Күкнең җиденче катында»

№1 гыйнвар, 2021 нче ел

## Мәктәп яңалыклары





20 нче гыйнвар көнне шәһәр **" Живая классика»** бәйгесенең мәктәп туры узды.

Ул 1-4 нче сыйныфлар арасында уздырылды.

Укучылар Е. Шварц, Ф. Достоевский, А. Волков әсәрләрен укыдылар.

## "Ут-күз куркынычсызлыгы"



22 нче гыйнвар көнне,"Ут-күз куркынычсызлыгы" буенча, 1-11 нче сыйныф укучыларына инструктажлар укылды.

- Элек заманда кеше утны ашарга пешерү, җылыту өчен уйлап тапкан. Шул ук вакытта утның куркыныч ягын да белгән. Янгында кешеләр, хайваннар, урманнар, авыллар янган.

-Янгын; урман янгыннары һәм аларның килеп чыгу сәбәпләре.

-Янгын сүндерүчеләр һөнәре.

Янгынны китереп чыгаручылар:

- Төзек булмаган электр приборлары.
- Шырпы белән уеннар.
- Петарда, бенгаль утлары.
- Сүндерелмәгән үтүк.
- Тиз янып китүче сыеклыклар: бензин, керосин, лак, буяулар, спирт.

Электр җиһазларын куллану кагыйдәсе:

- Резина янган ис сизсәң, төтенләүче чыбык күрсәң тиз генә зурларга әйт.
- Электр җиһазларын уттан өзәргә онытма.

Янгын куркынычсызлык кагыйдәләре:

1. Шырпы белән уйнама.
2. Киемне газ плитәсе янында киптерергә ярамый.
3. Өйдә бенгаль утлары, фейерверклар кабызырга ярамый.
4. Ачык мичкә якын килмә, капкачын ачма.
5. Урманда учак ягарга ярамый.
6. Өйдә төтен чыкса, ишекне ачарга, күршеләргә әйтергә.
7. Электр җиһазларын су белән сүндерергә ярамый. Башта уттан өзәргә, аннан калын одеял беләнябарга кирәк.
8. Янгын чыкса "01" телефонына шалтыратырга.

Янгын вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре:
Янгын вакытында һәркем каушарга, паникага бирелергә мөмкин.
- Янгын чыгуга 01 телефонына шалтырат, адресыңны әйт (урам, өй номеры)
- Өйдән яки фатирдан чык, күршеләргә әйт, ярдәмгә чакыр.
- Өйгә төтен чыкса, идәнгә иелеп чыгу юлына бар.

## Суыктан ничек сакланырга?

Табигатькә суыклары белән чын кыш килде. Кызганычка каршы, кешеләр суыкларда өшеп, сәламәтлекләренә зур зыян китерергә мөмкиннәр. Суыкта кысан өс һәм аяк киеме кию, ару, ачыгу, озак вакыт хәрәкәтсез тору, авыр чирдән соң организмның хәлсезләнүе, аяк тирләү, хроник чирләр өшүгә китерергә мөмкин. Өшүдән саклану өчен берничә киңәш.

Озак вакытка чыгып киткәндә берничә кат кием киегез. Үзегез белән өстәмә йон оекбаш, бияләй алыгыз. Суыкка чыгып киткәндә ныгытып ашагыз, үзегез белән кайнар чәй алу да комачауламый. Организмда калорий күбрәк булган саен, өшү куркынычы аз.

Аяк-кулларыгызның өшегәнен сизсәгез җылы бинага керегез. Өшегән тәнне җылытып йон бияләй яки шарф белән ышкыгыз, кар белән ышкырга ярамый. Өшегән кешене иң элек җылыга кертергә, өс-аяк киемнәрен салдырырга. Тәннең өшегән өлешен кайнар суда, җылыткычлар янында җылытырга, спирт, май сөртергә ярамый.

Суыкта зыян күрүченең өстенә юрган ябарга, кайнар чәй һәм аш, авыртуны басучы дару бирергә.

## Грипптан ничек сакланырга һәм ничек дәваланырга?
## (КИҢӘШЛӘР)

Авыруның беренче билгеләрендә үк 24 сәгать эчендә вируска каршы препаратлар, дарулар куллану файдалы.

Күп итеп су эчәргә, С витаминына бай ризыклар ашарга киңәш ителә. Мөстәкыйль дәваланырга ярамый. Табиб чакыртырга кирәк. Гадәттә, югары температура авыруның иммунитетына бәйле рәвештә 3-7 көн күзәтелергә мөмкин. Авырып китсәгез, өйдә калыгыз. Аеруча авырган балаларны балалар бакчасына, мәктәпләргә җибәрергә ярамый.

Вакытында дәваланмаган грипп пневмония, борын куышлыгы ялкынсынуы, нерв белән бәйле авыруларга китерергә мөмкин.


Истә тот!

Иммунитетны ныгыту мөһим, С витаминына бай ризыклар ашарга, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, дөрес тукланырга тырышыгыз.
Сеңгергән, төчкергәндә кулланган салфеткаларны шунда ук чүплеккә атарга кирәк, авыруның вирусы предмет өслегендә 12 сәгатькә кадәр сакланырга сәләтле.

# Эшлекле очрашу

Гарифуллина Динә - Казан шәһәре Думасының депутаты, София Гөбәйдуллина исемендәге заманча музыка үзәгенең директоры белән эшлекле очрашу












**Истәлекле даталар:**

***1 гыйнвар*** -Татар әдәбиятының классик шагыйре Һади Такташ (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев)ның тууына 120 ел (1901–1931)

***1 гыйнвар*** -Язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Адлер Камил улы Тимергалинның тууына 90 ел (1931–2013)

***2(15) гыйнвар*** -Композитор, педагог, профессор, СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре (1948, 1950, 1970) һәм Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Гаяз улы Җиһановның тууына 110 ел (1911 – 1988)

***2 гыйнвар*** - Шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Зәкиҗан улы Яхинга 60 яшь (1961)

***6 гыйнвар*** -Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты Габделфәрт Әхәт улы Шәрәфиевнең тууына 70 ел (1951–2014)

***7 гыйнвар***-Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшир улы Бәшировның тууына 120 ел (1901–1999)

***13 гыйнвар*** -Татар әдәбияты классигы – прозаик, драматург, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов)ның тууына 135 ел (1886–1926)

***13 гыйнвар*** - Шагыйрь, педагог, филология фәннәре кандидаты, Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Хәнәфи Габделбәр улы Бәдигыйга (Бадыйковка) 80 яшь (1941)

***15 гыйнвар*** -Шагыйрь, ТАССРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Илдус Сабир улы Гыйләҗевнең тууына 75 ел (1946–2018)

***29 гыйнвар*** -Драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Аяз улы Гыйләҗевкә 60 яшь (1961)

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
**Редколлегия әгъзалары:**
Зактирова Азалия, Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Соколова София